РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИСАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСӘК
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» июль 2017 ел № 8

« Карарны гамәлдән чыгару турында»

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003елның 6 октябрендәге 131-ФЗ Федераль Законына, "Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында" 28.12.2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ Федераль Законына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016елның 13 августындагы 553 номерлы "Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында" карары нигезендә Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 10 апрелендәге 6 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карар имзаланганнан соң законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән игълан ителергә тиеш (http://buinsk.tatarstan.ru).
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Исәк
авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе З.Р. Мухаметзянова